СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

06.05.2025 г. Заинск № 395

**Зәй муниципаль районы Советының 2018 елның 13 апрелендәге 279 номерлы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Зәй муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең 1998 елның 31 июлендәге 145 номерлы Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасының 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Кодексы нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы Советының 2018 елның 13 апрелендәге 279 номерлы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Зәй муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына (Зәй муниципаль районы Советының 22.10.2018 ел № 341, 27.08.2020 № 553, 27.12.2021 № 193, 27.09.2022 № 234, 18.11.2022 № 244, 13.06.2024 № 333, 09.12.2024 № 362 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Күрсәтелгән карар белән расланган Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисенә, рәис урынбасарына, аудиторларына, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә:

2.2 пунктта «13 990 сум» сүзләрен «15 389 сум» сүзләренә алмаштырырга.;

2.6 пунктта «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Күрсәтелгән карар белән расланган «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторларының, Зәй муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында» нигезләмәгә 2 нче кушымта бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

4. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Билгеләргә:

әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә;

әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары П. С. Уразайкинга йөкләргә.

**Совет рәисе** **Р.Г. Кәримов**

Татарстан Республикасы Зәй
муниципаль районы Советы
карарына кушымта
06.05.2025 елдан № 395

Айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфа исемнәре | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 4 төркем |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы | 42 778 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 38 498 |
| Депутатлар | 20 733 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 17 621 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 38 498 |
| Контроль-хисап органы рәисе урынбасары | 34 623 |
| Контроль-хисап органы аудиторы | 28 008 |